## Сугыш

**“Сугыш” дигән куркыныч сүз**

**Шакыды ишекләрне.**

**Ил сакларга күпме солдат китте,**

**Тетрәндереп йөрәкләрне.**

**Әй, син, кырыс сугыш,**

**Өзелә бит синдә гомерләр.**

**Бөркет кебек ирләр башын сала,**

**Ятим кала сабый балалар.**

**Күпме ана йөрәк ярсуына,**

**Түзә алмый. Көтә баласын.**

**Күңелләрне тетрәндереп тора**

**Ачы сагыш, сугыш һавасы.**

**«Без кайтабыз» диеп китеп барсалар да,**

**Тик күбесе исән кайтмады.**

**Сәламләсен сер бирмәгән җиңү**

**Батыр җанлы кыю халкымны.**

**Фронт кырында бүген сугышканнар,**

**Исән-имин кайтып керсеннәр.**

**Сынамасын бүтән берүк язмыш,**

**Солдат гомере тормыш күрсеннәр.**

***Раилә Гирфанова***